ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 август 2020ел № 3935

Башкарма комитетның 2013 елның 7 августындагы 4713 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 7 августындагы 4713 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3274 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2396 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6594 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 пунктта икенче баганаы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган:

- аерым затның элек булган (хәзерге) күчемсез милек объектына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

- күчемсез милеккә хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә»;

2) 3 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 13 августындагы
3935 номерлы карарына
кушымта

Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен гариза бирүчене һәм аның гаиләсен исәпкә алу турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен кирәкле документлар исемлеге

1. Барлык гражданнар өчен гомуми нигезләрдә:

гражданның Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә гаризасы;

финанс-шәхси счет күчермәсе;

торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар;

торак шартларын тикшерү турында белешмә (тузган һәм авария хәлендәге торак өчен);

ордер (наем, икенчел наем, аренда, субаренда шартнамәсе);

гаиләнең барлык эшләүче әгъзаларының эш урыныннан предприятие реквизитларын, гражданның эш урыны, аның вазыйфасы турында мәгълүматларны үз эченә алган, җитәкче тарафыннан имзаланган һәм оешма мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракта) белешмә(-ләр);

гаиләнең барлык әгъзаларының керемнәрен раслый торган документлар:

- алдагы ел өчен хезмәт хакы турында белешмә (2-НДФЛ формасы буенча);

- алдагы календарь ел һәм агымдагы календарь елның алдагы хисап чоры өчен салым инспекциясе билгесе куелган декларация (эшмәкәр өчен) яки йөкләтелгән керем түләүгә күчкән шәхси эшмәкәрләр өчен йөкләтелгән керемгә салым түләү турында таныклык (соңгы 6 ай өчен);

студент билеты яки уку урынын раслый торган документ (укучылар өчен);

стипендия алу турында белешмә (студентлар өчен);

пособиеләр алу турында белешмә;

Россия Федерациясе субъекты ягыннан субсидияләр булган очракта - субсидияләүне гарантияли торган документлар;

милектә торак булу яки аны тартып алу буенча килешүләрне гамәлгә ашыру турында белешмә (гариза бирүченең торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән барлык затларга, шул исәптән Россиянең башка төбәкләреннән, соңгы 5 ел өчен);

торак урынга һәм җиргә хокук билгеләүче документларның күчермәләре (торак урынга һәм җиргә милекчелек турындагы таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе һ.б.);

Техник инвентаризация бюросы тарафыннан бирелгән торак урынының (фатирның) техник паспорты, янәшә (янәшә-изоляцияләнгән) бүлмәләрдә яшәүчеләр исемлеге;

Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсендә күчемсез милекне теркәү турында таныклык;

әлеге мәйданда яшәүче барлык гаилә әгъзалары өчен - паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), гаиләнең балигъ булмаган әгъзалары өчен – туу турында таныклык;

хәрби хезмәткә яраклы ир-атлар өчен – хәрби билет күчермәсе;

хезмәт стажын раслый торган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (кадрлар бүлеге башлыгы тарафыннан расланган барлык битләр) яки тиешле рәвештә кәгазьдә расланган яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (эш бирүчедә булганда) электрон документ формасында хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат;

туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар: язылышу (аерылышу) турында таныклык, бала туу турында таныклык, никах контракты булу;

гаиләнең һәр әгъзасының ИНН (салым түләүченең идентификация номеры) күчермәләре.

2. Яшәү өчен яраксыз торак урын биләгән гражданнар өчен:

1 пунктта күрсәтелгән документлар;

Бүлмәнең (күпфатирлы йортның) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында бәяләмә.

3. Ташламаларга ия гражданнар өчен:

1 пунктта күрсәтелгән документлар;

тиешле ташламаны раслый торган дәүләт циркуляры;

тиешле ташламаны раслый торган документлар: белешмәләр, таныклыклар;

әлеге хокукны исәпкә алып, чиратка кабул ителә торган затлар өчен өстәмә мәйданга хокук турында документлар.

Искәрмә:

Кирәк булган очракта, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары турында өстәмә белешмәләр булган документларны соратып алырга хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева